ЧӘЧҮ КӨТКӘНДӘ

Игенчеләр, кыр эшләренә тотынуга көннәр суытып җибәрмәсме, дип борчыла

> 2

ЕЛ УКЫТУЧЫСЫ

Иннополис лицеенда белем бирүче 28 яшьлек математика укытучысы Арман Костанян шундый дәрәҗәле исемгә лаек булды

> 3

КӨЙМӘ КИРӘК

Татарстанның кайбер авыллары – су эчендә

> 4

АЛКАЛЫ КӨРӘШ

«Ак барс» командасы КХЛның көнчыгыш конференциясе финалына үтте

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 43 (29010) | Сишәмбе | 28 март | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

БАЛА ХАКЫ

ҖӘЙГЕ ЯЛ ӨЧЕН ТАГЫН ДА ТЫРЫШЫБРАК ЭШЛӘРГӘ ТУРЫ КИЛӘЧӘК

Бу җәйне авылда әби-бабасы янында үткәрәчәк оныклар саны бермә-бер артып китмәгә. 2020 елдан бирле ил күләмендә гамәлдә булган һәм әти-әниләргә балалар ял лагерена юллама сатып алган акчаның яртысын кире кайтару мөмкинлеге биргән кешбэк программасы быел озайтылмады. Димәк, өлкәннәргә балалар ялын үзләренә кайгыртырга туры киләчәк. Бу җәйдә ял күпмегә төшәчәк?

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Ике улым да спорт мәктәбендә шөгыльләнә. Каникул саен ял лагерена барулары – гадәти хәл. Укудан бушаган арада шул рәвешле спорт күнекмәләрен ныгыталар. Спорт мәктәбендә лагерьга бару, кем әйтмешли, ихтыяри-мәҗбүри. Узган ел җәй көне ике баламның һәркайсына 27 мең сум акча түләп, бер сменага (18 көн) ял итәргә җибәрдем. Балалар кешбэк программасы гамәлдә булгач, түләгән акчаның яртысы кире кайтты. Быел исә әлеге программа булмаячак, диләр. Тренер бу хакта алдан ук кисәтеп, балаларның җәйге ялына акча җыя торырга киңәш итте. Тик бу кадәр акчаны кайдан аласы? – ди Казанда яшәүче Венера Зәйнуллина.

Аның кебек хафага төшкән әти-әниләр шактый. Билгеле булганча, ил буйлап сәяхәт итәргә теләүчеләргә һәм балалар ял лагерьларына баручыларга ташламалы дәүләт программасы 2020 елның августында гамәлгә керде. Аның максаты да билгеле. Пандемия аркасында шактый кыен хәлдә калган туризм тармагын янә аякка бастыру өчен халыкны юллама бәясенең яртысын (әмма 20 мең сумнан да күп түгел. – **Ред.**) «Мир» картасына кире кайтару тәкъдиме белән кызыктырдылар. Ике як өчен дә отышлы, кыскасы. Узган ел нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда балалар ял лагерьларына юллама сатып алган әти-әниләр кешбэк программасы ярдәмендә 500 миллион сумга якын акчасын янга калдырган. «Алдагы ел белән чагыштырганда, 2022 елда кешбэк программасы буенча балалар ял лагерьларына юллама сатып алучылар саны ике тапкыр артты. Июнь башында барлык юлламаларның 80 проценты сатылып беткән иде инде», – дигән иде ул вакытта яшьләр эшләре министры вазыйфасын башкарган Тимур Сөләйманов.

Һәм менә рәхәткә өйрәнгәч кенә, ташламалы программаны бетерделәр. Дөрес, бу хакта рәсми рәвештә кистереп әйтүче юк. Федераль казнада моның өчен акча каралмаган, шул гына. Аңлашыла ки, бүген акчага болай да урын күп. Илнең стратегик эшләнмәләр үзәгенең Икътисадый һәм социаль үсеш юнәлеше җитәкчесе Виктория Павлюшина сүзләренә караганда, кешбэк программасы – пандемия һәм илдә махсус хәрби операция игълан ителү чорында туризм тармагына күрсәтелгән вакытлыча ярдәм чарасы гына иде. Бүген исә тармакта вазгыять тотрыклы, дигән ул. Дөрес, моның белән килешмәүчеләр дә бар.

– Без 2019 ел күрсәткечләре дәрәҗәсенә җитмәдек әле. Ул вакытта ил буенча 65 миллион турист сәяхәт итсә, кешбэк ярдәмендә былтыр илгә килгән кунаклар саны 61 миллион чамасы тәшкил итте. Әгәр быел программа эшләмәсә, без туристларның 15 процент чамасын югалтачакбыз, – ди Россия туризм индустриясе берлеге җитәкчесе Илья Уманский.

Татарстанның туризм буенча дәүләт комитеты җитәкчесе Сергей Иванов әйтүенчә, әлеге программа туристлар санын арттырырга нык ярдәм иткән.

– Былтыр, мәсәлән, Казан туристик кешбэк программасы буенча сәяхәт итүчеләр саны буенча Краснодар крае, Санкт-Петербург, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсе белән берлектә, беренче бишлеккә эләкте. Республика федераль программада актив катнашты. Ул бигрәк тә шифаханәләр, круиз компанияләре һәм балалар лагерьлары өчен отышлы булды, – диде ул.

Моны юллама сатучылар үзләре дә раслый.

– Кешбэк федераль программасы Казан шәһәре муниципаль лагерьларында 2021 һәм 2022 елларда гамәлдә булды, – ди башкалада дистә елга якын балаларның ялын оештыру белән шөгыльләнүче «Ял» үзәге директоры Константин Крайнов. – Әйтергә кирәк, ташламалы программаны әти-әниләр бигрәк тә яратып кабул итте. Узган ел нәтиҗәләренә караганда, кешбэктан 10 меңгә якын әти-әни файдаланган. Быел программаның язмышы билгесез. Бу хакта бернинди рәсми мәгълүмат та юк. Ничек кенә теләсәк тә, без федераль программаны гамәлдә калдыруга тәэсир итә алмыйбыз шул.

Ахыры 2 нче биттә >

Рәсми мәгълүматларга караганда, былтыр Татарстанда балалар лагерена юлламаның уртача бәясе тәүлегенә – 1191,3 сум, ягъни 18 көнлек бер сменага 21,4 мең сум тәшкил иткән. Республика балалар сәламәтләндерү лагеренда ялның бер сменасы – 21,3 мең сум, муниципаль лагерьда – 18,2 мең сум, коммерцияле оешмалар өчен 24,7 мең сум торган.

Паспорт смартфонга күчә

Президент Владимир Путин гадәти паспорт урынына цифрлы таныклыкны гына күрсәтү мөмкинлеген күздә тоткан указ проектын әзерләү бурычын куйган. Кремль сайтында хәбәр ителгәнчә, бурыч 1 майга кадәр үтәлергә тиеш. Премьер-министр Михаил Мишустин, Иминлек федераль хезмәте директоры Александр Бортников һәм эчке эшләр министры Владимир Колокольцев бу эшкә җаваплы итеп билгеләнгән. Президент моннан бер ай элегрәк Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының кәгазь документ урынына смартфоннарга цифрлы таныклык кертү тәкъдимен хуплаган иде.

Исегезгә төшерәбез: Хөкүмәт 2021 елның декабрендә цифрлы паспортны гамәлгә кертү өчен Мәскәү өлкәсен, Мәскәү һәм Татарстанны пилот төбәкләр сыйфатында сайлап алды. Агымдагы ел башыннан бу төбәкләрдә цифрлы паспортлар бирү күздә тотылды. Ләкин узган елның июнендә Мәксут Шадаев цифрлы паспортлар бирү проектын «катыру» турында белдергән иде.

Әйбәт алып эшлиләр

Татарстан кечкенә һәм уртача зурлыктагы шәһәр-бистәләрдә хезмәт хакы буенча Россиянең иң алдынгы 20 төбәге исәбенә кергән. «РИА Новости» агентлыгы хәбәр иткәнчә, узган елда республикада уртача хезмәт хакы 48,3 мең сум тәшкил иткән. Шул рәвешле ул алдагы елдагы белән чагыштырганда 18 процентка арткан. Республиканың кечкенә һәм уртача зурлыктагы торак пунктларында хезмәт хакы зур шәһәрләрдәгенең 76,8 процентын тәшкил иткән.

Мондый шәһәр-бистәләрдә яшәүчеләр төньяк һәм ерак көнчыгыш төбәкләрдә: Магадан өлкәсендә (116,9 мең сум), Ямал-Ненец (115,7 мең сум), Ханты-Манси (89,6 мең сум) һәм Чукотка (122 мең сум) автономияле округларында иң күп акча алып эшли.

Узган елда илдә халыкның кереме тулаем 1,4 процентка кимегән. Әмма 12 төбәктә, шул исәптән Татарстанда арткан (2,1 процентка). Бу – ил буенча бишенче күрсәткеч.

Башлана

30 мартта балаларны беренче сыйныфка алу башлана. Мәгариф һәм фән министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, быел Татарстанда 53 меңнән артык малай-кыз беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керергә тиеш.

Мәктәпкә беркетелгән территориядә яшәүче, шулай ук өстенлекле, беренче чираттагы яки чираттан тыш хокукка ия балалар өчен документлар 30 марттан 30 июньгә кадәр кабул ителәчәк. Ә инде теркәлү урыны буенча якындагы мәктәп ниндидер сәбәпләр аркасында канәгатьләндермичә, балага башка райондагы уку йорты белешеп куелса, 6 июльгә кадәр көтәргә туры киләчәк.

Мәктәп җитәкчелеге сыйныфларда буш урыннар булмаган очракта гына баланы кабул итүдән баш тарта ала. Документлар буш урыннар тулганчы, әмма 5 сентябрьдән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Кызганычка, баланы бирергә теләгән мәктәптә урыннар саны анда укырга теләүчеләр санынннан азрак булып чыгарга да мөмкин. Бу очракта яшәү урыны буенча Мәгариф идарәсе органнарына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Алар ата-аналарга баласын башка мәктәпкә урнаштырырга ярдәм итәргә тиеш.

Рәттән өч рекорд

Татарстанда узган ял көннәрендә – 24–26 мартта тәүлеклек уртача температура нормадан 8–12 градуска югарырак булган. Безнең төбәктә мондый һава торышы гадәттә апрель азагында гына күзәтелә. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, Казанда шушы 3 көндә һава температурасы берничә рекорд куйган. Һава торышын күзәтү тарихында беренче тапкыр шуның кадәр җылы булган. 24 мартта Казанның Идел буе районы метеостанциясе +11,8 градус күрсәткән. Шул рәвешле 2014 елда куелган рекорд (10,5 градус) узылган.

25 мартта Казанда һава температурасы +9,9 градуска җиткән. Элекке рекорд шул ук 2014 елга карый (9,4 градус). Ә 26 мартта һава +14,7 градуска кадәр җылынган (2020 елгы рекорд +11,9 градус).

Мондый һава Татарстанга җылы циклон үтеп керүгә бәйле. Республика буенча һава температурасы 24 һәм 25 мартта +8...+14, 26 мартта +14...+18 градуска кадәр күтәрелгән.

Март ахырында да җылы һава сакланачак. Вакытлыча яңгырлар һәм урыны белән көчле җил булырга мөмкин. Чәршәмбе – 29 мартта явым-төшем ихтималы аз. Көндез +6...+11 градус, төнлә суыта: +2...–3 градус. Пәнҗешәмбе – 30 мартта көндез аз гына яңгыр булачак, урыны белән секундына 15–20 метр тизлектә көчле җил көтелә. Һава температурасы көндез +8...+13 градус, төнлә +4...–1 градус.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга – 31 март һәм шимбә 1 апрельдә аз гына явым-төшемле, җилле җылы һава сакланачак. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +8...+13, төнлә +1...+6 градус күрсәтәчәк.

Менә шундый хәлләр

Озаграк яшибез

Россиядә фаразланган гомер озынлыгы рекордлы күрсәткечкә җиткән. Алдан ук искәртеп узыйк: фаразланган гомер озынлыгы дигәндә, үлем-китем күрсәткечләре шул ук дәрәҗәдә сакланган шартларда кеше яши алган гомер озынлыгы күздә тотыла. Узган ел нәтиҗәләре буенча ул илдә 72,76 яшь тәшкил иткән. Бу 1990 нчы еллардан бирле теркәлгән иң зур күрсәткеч дип бәяләнә. Бер ел эчендә Татарстанда да гомер озынлыгы, 3,6 елга артып, 74,93 яшькә җиткән, дип белдерә Росстат белгечләре.

Бер ел эчендә Россиядә барлык төбәкләрдә дә диярлек гомер озынлыгы арткан. Ингушетиядә генә кимү күзәтелә: анда 2,15 елга азаеп, 78,37 яшь тәшкил иткән.

Росстат белгечләре хәбәренчә, соңгы ике елда пандемия аркасында илнең һәр төбәгендә диярлек күрсәткечләрнең кимүе күзәтелгән. Саннар теленә күчсәк, тормышыбызда «коронавирус» дигән зәхмәт пәйда булган 2020 елда илдәге көтелгән гомер озынлыгы – 1,8 елга, 2021 елда 1,4 елга кимегән булган. Шушы ике елда илдә үлүчеләр саны да кискен арткан. 2020 елда үлем-китем очраклары 19 процентка арткан булса, 2021 елда – 36 процентка.

Узган ел Идел буе төбәкләре арасында иң түбән үлем-китем күрсәткече Татарстанда теркәлгән. Республикада 1 мең кешегә 11,5 үлем очрагы туры килә. Яман шеш белән кан әйләнеше системасы авырулары әле дә булса үлемгә китергән иң төп авыруларның берсе булып кала бирә.

ФАРАЗЛАНГАН ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ИҢ НЫК АРТКАН ТӨБӘКЛӘР

Төбәк	Күпмегә арткан, ел	Гомер озынлыгы, яшь
Саратов өлкәсе	+3,79	72,87
Татарстан	+3,65	74,93
Мәскәү	+3,64	78,19
Рязань өлкәсе	+3,59	72,2
Липецк өлкәсе	+3,55	72,13

Сүзгә-сүз

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ, Татарстан Рәисе:

Тоткан уразаларыгыз, кылган догаларыгыз кабул булсын! Рамазан ае мөбарәк булсын! Һәркайсыгыз ифтар уздырса, яхшы булыр иде. Очрашу, аралашуның бик яхшы формасы бу. Аллаһы Тәгалә изге гамәлләребезне күрә.

(Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдән)

ТАТАРСТАНДА ЭШЛӘҮЧЕЛӘРНЕҢ БЕЛЕМ ДӘРӘҖӘСЕ



Татарстанстат мәгълүматлары буенча

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

МИНИСТР БАШЫНА – ПОЛИЦИЯ КҮСӘГЕ

Банк кризисы һәм финанс түнтәрелеше дәвам иткән үткән атнада дөнья яңалыклары авансценасына Израильдәге гыйбри фетнәсе чыкты. Мин алдагы язмаларда алардагы хәлләрнең начар булуын хәбәр иткән идем. Үткән елларда Тель-Авивта һәм башка шәһәрләрдә гыйсъянчылык уты яман кызды. Талаш Нетаньяху хөкүмәте уйлап чыгарган суд реформасын сылтау итеп башланса да, сәбәпләр тирәндәрәк. Алар тирән әхлакый кризис кичерә. Шуның өстенә финанс кризисы да якынлаша. Нәтиҗәдә халыкның тормышы авырлаша. Израильдә «Paamonim» дип аталган коммерцияле булмаган оешма бар. Аның төп максаты – фәкыйрьләргә булышу. «Paamonim» хәбәр итүенчә, бүген израильлеләрнең 22 проценты дару сатып ала алмый, гаиләләрнең 41 процентының эшсез калган очракта өч ай гына җан асрарлык рәте бар. Менә шулар тышка бәреп чыга инде. Фәкыйрьләнүче җәмгыять белән идарә иткән Нетаньяху хакимлек дилбегәсен ычкындырудан курка, чөнки аның эше – судта, элекке җинаятьләре өчен җавап бирәсе бар. Идарәдән киттеңме, төрмә ишекләре ачылачак. Шуннан котылу өчен, Биньямин Нетаньяху суд реформасы һәм Премьер-министр статусын үзгәртүче закон уйлап чыгарды. Соңгысы нигезендә Премьер-министрны бар халык каршы тавыш бирсә дә, ул хәтта акылдан язса да, зур җинаять эшләсә дә, хакимлектән алып ташлау мөмкин түгел диярлек. Элиталарның җен ачуын чыгарды ул реформалар, болай да үчле халыкны баррикадаларга чакырдылар. Хәтта гамәлдәге кабинетның кайбер министрлары да Нетаньяхуга кискен каршы чыкты. Оборона министры Йоав Галант, суд реформасы илнең оборона сәләтен юкка чыгара, дип белдерде, реформаны туктатуны таләп итте, шуның өчен эшеннән алынды. Оборона министрын идарә итүче партиянең кайбер башка лидерлары да яклады. Интригалар сөйләп бетерерп булмаслык дәрәҗәгә җитте. Бу урам протестының кызуына китерде. Баш күтәргән меңләгән кеше аздан гына хөкүмәт башлыгының өенә бәреп кермәде. Шәһәр урамнарында учаклар дөрләде. Лидерны яклаучы журналистлар да аның стратегик хата ясавын игълан иттеләр. Элекке Премьер-министр Беннет: «Израиль кыямәт көне сугышы чорыннан (1973 елгы гарәп-гыйбри сугышын Израильдә шулай атап йөртәләр, чөнки ул чакта гарәпләр аздан гына гыйбриләрне тар-мар итми калдылар) соң иң хәвефле хәлдә», – дип белдерде. Протест оештыручылар башланып килүче атнаны «Милли паралич атнасы» дип игълан итте. Табиблар, укытучылар эшкә чыгудан баш тартты. Берничә ай элек кенә Израильнең эчке куркынычсызлык министры булган Омер Бар-Лев та протест акциясенә кушылып урамга чыккан иде, башына полиция күсәге төште. ЛГБТ-җәмәгатьчелек урамга миллионлаган кешене чыгарачагын белдерде. Халкы тугыз миллионга тулмаган илдә миллионлаган гей урамга чыга икән, анда кемнәр яшәве аңлашыла инде. Вазгыять лидер өчен куркынычка әверелде, шуңа күрә реформа тәгәрмәчен артка бору мөмкин түгел, дип нык торган хөкүмәт башлыгы законның туктатылуы турында игълан итәргә җыена.

Россиядә

АЛТЫН ЧЫГАРЫП БАЕРГА

Яшәгән кешегә эш бар. Компанияләр эшкә кеше алу планын арттырган. Эшче, инженерлык белгечләре, авыл хуҗалыгында эшләүчеләр күп кирәк. Импортны алыштыру белән шөгыльләнүчеләр дә таләп ителә. Әмма реаль хезмәт хаклары бик үсми, диләр. Авыл хуҗалыгында әллә ни үсә дә алмас, чөнки җитештергәнгә бәя түбәнәя. Федераль Авыл хуҗалыгы министрлыгы көнбагыш маен, көнбагышны һәм бодайны читкә сатмаска киңәш итә, бәяләр түбән. Көнбагыш маеның бәясе тоннага 1100 доллардан 800 долларга кадәр, көнбагышныкы 600дән 395 долларга кадәр түбәнәйгән. Арзанга сатасы килми, кыйммәткә алучы юк. «Ашлыкны кая куярга соң?» дигән сорау борчый фермерларны.

Бер аларны гына түгел, алюминий короле Дерипасканы да «Ничек яшәргә?» дигән сорау йөдәтә. «Бездә җитди икътисадый үсеш тә, халыкның төп төркемнәренең кереме үсү дә юк. Көнчыгыш Африка бабуиннары кебек очны очка ялгап, нефть һәм газ рентасы хисабына яшибез», – дип зарлана ул. Дерипаска Путин чыгышларын тыңламый, димәк.

Чынлап та, әлегә чимал табышына яшәргә туры килә. Быелның беренче ике аенда Кытайга платина сатуны 265 тапкыр арттырганбыз. Дөрес, күп акча кермәгән, бары 53 миллион доллар гына. Технологик продукция белән алга чыгып булмый әле. AYYA T1 дип аталган үзебездә җитештерелгән смартфоннарны сатуга чыгарып карадылар, аны «Россиянең айфоннарны үтерүчесе» дип зурлаганнар иде. Тик алар ил күләмендә бары 905 данә генә сатылган. Бәясен 60 процентка төшерү дә булышмый.

Смартфоннар сатмасак, якын киләчәктә алтын чыгарып баеп булыр. Путин тәкъдиме белән Хөкүмәт комиссиясе Дәүләт Думасына алтын эзләүчеләр эшчәнлеге турында закон проекты кертте. Якындагы өч елда башта Ерак Көнчыгыш һәм Арктикада шәхси затлар алтын эзли һәм чыгара ала башлаячаклар. Аннан соң бар илгә җәеләчәк. Канун проекты авторлары аның яңа эш урыннары булдырасына һәм бюджетны акча белән тутырасына ихлас ышаналар. Якын-тирәдәге алтын ятмаларын барлый торырга вакыт, димәк.

vk.com

Ният

МӘДӘНИЯТЛЕ БАШКАЛА

2023 ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

«Татарстанның мәдәни башкаласы» дигән исем һәм 3 млн сум акча! Республиканың бер районына әнә шундый бәхет елмаячак икән. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында Татарстанда яңа бәйге игълан ителә.

tatarstan.ru

Бер карасаң, бар да гади. Районнар аларга гына хас үзенчәлекләрне күрсәтергә тиеш. Тарих та, мәдәният тә булсын анда, милли аш-су, традицияләр, кәсепләр дә, остаханәләр дә. Районнардан күргәзмә дә сорала. Әлбәттә, җыр-бию, концертсыз да булмый. Тагын бер юнәлеш – туристик маршрутлар. Менә шуларның барысын да колачлап, республиканың һәр районы махсус программаны Казанга алып киләчәк. Алар башкаланың 13 мәйданчыгында ел дәвамында – 31 марттан 24 ноябрьгә кадәр чыгыш ясар дип көтелә.

Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, милләтләрнең мәдәни үзенчәлеге республиканың социаль юнәлештә алып барыла торган эшчәнлегендә аерым урынны алып тора. Сүз уңаеннан, Татарстанда игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында 300дән артык чара үтәр дип көтелә. Ләйлә Фазлыева искәрткәнчә, алар төрле юнәлешләргә бүленгән. Әйтик, фән, бәйрәмнәр, мәдәният, инфраструктура үсеше һәм башкалар.

Конкурска әйләнеп кайтыйк. Ләйлә Фазлыева сүзләренчә, 31 мартта Казанга үзенчәлекле программасын Лениногорск районы алып киләчәк. Чара Халыклар дуслыгы йортында узачак.

– Мәдәният ул – теләсә кайсы халыкны һәм кешене беренче чиратта тасвирлый торган төшенчә. Шуңа күрә бу мәсьәләгә аерым игътибар бирелә дә, – диде Ләйлә Фазлыева. – Бу конкурста катнашачак районнар 3 млн сумлык сертификат өчен дә ярыша. Шик юк, районнарның күрсәтерлек тә, сөйләрлек тә нәрсәләре күп.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин әйтүенчә, әлеге проект – Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында булачак мөһим чараларның берсе.

– Республикабызда мондый тәҗрибә элек бар иде. Советлар чорында һәр район үзенчәлекләрен күрсәткән. Ә бит, чынлап та, үзенчәлекләр бар. Әйтик, чәкчәк тә төрле җирдә төрлечә әзерләнә. Кайдадыр бавырсак дип тә атыйлар, кайдадыр балын күп итеп салалар. Шуңа күрә районнарга үзләрен күрсәтер өчен бер мөмкинлек бу, – ди министр урынбасары.

Районнар алып килгән программа белән танышу бушлай. Халыкка ошап китсә, проектның озын гомерле буласына да ишарә ясадылар. Районнарның осталыкларын бәяләү өчен Татарстанның Иҗтимагый палатасы һәм Ресурс үзәге вәкилләре чакырылган. Ә катнашучыларның профессионализмнан битәр, тирән эчтәлекле программасына күбрәк игътибар биреләчәк.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Бала хакы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә.

«Ял» шәһәр үзәгенә унбер балалар лагере керә. Җәйгә юлламаларны 6 апрельдән сата башларга ниятлиләр. Сүз уңаеннан, былтыр балалар кешбэк программасы ярдәмендә җәйгә юлламалар сатып алу 31 марттан башланган иде. Казанга якын, яшәү шартлары яхшы булган лагерьларга юлламаларны көне-сәгате белән алып бетерделәр.

– Узган ел белән чагыштырганда, юллама бәяләре үзгәрмәде диярлек. Әти-әниләрнең матди мөмкинлекләреннән чыгып эш итәргә тырышабыз. Мәсәлән, быел җәй көне 18 көнлек ял бәясе 9 мең сумнан 13 мең сумга кадәр тәшкил итәчәк. Казан оешмалары һәм предприятиеләреннән ялга баруның бер сменасы 40 мең сумга кадәр җитәчәк. Инде хәзер үк әти-әниләр арасында юллама сатып алуга сорау зур икәнен сизәбез. Федераль программадан башка да бу җәйдә лагерьларда урын калмаячак, – ди Константин Крайнов.

Узган елдан аерма шунда гына: быел лагерьга юллама бәясе тулысынча әти-әниләр җилкәсенә төшәчәк. Россия Дәүләт Думасының Туризм һәм туристик инфраструктураны үстерү комитеты җитәкчесе Сангаджи Тарбаев сүзләренә караганда, программаны берникадәр үзгәртеп, янә гамәлгә кертергә дә мөмкиннәр. Мәсәлән, ул аз керемле гаиләләргә яки Кырым кебек аерым төбәкләргә ял итәргә барырга теләүчеләргә ярдәм чарасы булып калырга мөмкин. Тик соңгысы әлегә, кем әйтмешли, суга сәнәк белән генә язылган.

Мәсьәләгә ачыклык кертүләрен сорап, Татарстан Яшьләр эшләре министрлыгына да шалтыраттык. Чөнки балалар ял лагерьлары белән нәкъ менә алар эшли. Тик министрлыкта әти-әниләрнең күңеленә сары май булып ятарлык бер генә җылы сүз дә әйтмәделәр.

Эльвира ВӘЛИЕВА

УРМАННАРГА... КЕРМӘ

Яшәеш

Яз иртә килү аркасында урманнарга керүне чикләргә мөмкиннәр. Узган ел урманнарда янгынга каршы махсус режим 25 апрельдә башланып, 15 октябрьгә кадәр, 174 көн дәвам итте. Татарстанның урман хуҗалыгы министры урынбасары Илгизәр Зарипов, быел бу режим иртәрәк, апрельнең беренче ункөнлегендә үк кертелер, ди.

Яз көне коры үләнне яндырмаячаклар. Басу-кырларда эшлисе бу эшләрне көзгә күчерәләр. «Иртә яз үз төзәтмәләрен кертте. Көннәр болай җылы торса, җир кибәчәк. Ә кипкән үлән янгынга сәбәп булып тора», – диде министр урынбасары «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Янгынга каршы махсус режим кертелгәч, басулардагы коры үләнне яндыру тыела. Моны фермер хуҗалыкларына да рөхсәт итмәячәкләр. Чүп яндыру очрагы теркәлсә, алар дәүләттән бирелгән субсидиядән колак кагарга мөмкиннәр. Штраф та каралган. Тәртипне җәяүләп йөреп тә, күктән дә күзәтәчәкләр.

– Без авыллардагы җыеннарда да катнашабыз. Республиканың һәр районында булдык. Бар кешегә дә урманнарны сакларга кирәклеге хакында сөйлибез. Янгын куркынычы чорында аеруча сак булырга кушабыз. Шырпы үзеннән-үзе сызылмый. Урман янгыннарының 10 очрагының тугызы кеше гаебе белән килеп чыга. Без, урманчылар, урман янгыннарын булдырмаска әзер, – ди Илгизәр Зарипов. – Җирләрнең хуҗалары бар. Эшмәкәрләрме, арендалап торучымы, юридик оешмалармы, үзидарә органнарымы, фермер хуҗалыкларымы – барысы да үз мәйданнарын коры үләннән чистартырга тиеш. Әлеге урыннардагы ягулык-майлау материаллары урманнан 10 метр читтә сакланырга тиеш. Шулай ук урман белән 1,4 метр арада минераллашкан полосалар ясап кую кирәк.

«Татар-информ»

Илгизәр Зарипов быел тәртип бозучыларны күктән күзәтүгә аерым тукталды. Күзәтү маршрутлары артачак икән. Урманчылар күктән 1 миллион 224 мең гектар җирне карап торачак. Министр урынбасары шулай ук янгынга каршы тору өчен, кирәк-яраклы бар техникабыз бар, дип тә ышандырды. Аның сүзләренчә, республика районнарында урнашкан төрле типтагы 25 урман янгыннарын сүндерү станциясенең ярдәме зур. Министрлыкка коры үләнгә ут кабу хакында да хәбәр шул ук минутта килеп ирешә. Биредә космостан күзәтү җайланмасы урнашкан. Диспетчерлык үзәге әлеге хәбәрне шундук урманчылыкларга җибәреп, утка ерак китәргә юл куймый. Янгын сүндерү машиналары да вакытында килеп җитә.

– Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе бүлеге белән берлектә эшлибез. Урман янгыннарына каршы безнең тармактан 1602 кеше һәм 598 техника, МЧСтан 856 кеше һәм 774 техника әзер тора. Бу чорда кешеләрнең урманга керми торуларын сорар идек. Урман янәшәсеннән узучы автомобиль юллары янында халык ял итсен өчен махсус урыннар әзерләп куябыз. Ял итәргә шунда туктасыннар. Чүп ташлау урыннары да бар. Кешеләр игътибарлы булсын иде. Кайчак бер минутлык шаяру күпме зыян сала. Табигатьне бергәләп сакласак иде, – ди Илгизәр Зарипов.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозган өчен гади кешеләргә – 30 мең, вазыйфаи затларга – 50 мең, юридик затларга 400 мең сумга кадәр штраф каралган. Әгәр янгын урман байлыкларына зыян сала икән, моның өчен җинаять җаваплылыгы каралган. Янгынга каршы махсус режим кертелгән чорда штраф күләме дә арта. Гади кешеләргә – 40 меңнән 50 меңгә, вазыйфаи затларга – 60 меңнән 90 меңгә, юридик затларга 600 меңнән 1 миллион сумга кадәр штраф салына.

Урманда ярамый:

- учак ягу;
- янган шырпы, тәмәке төпчеге, пыяла шешәләр ташлау;
- бензинга, керосинга, гомумән, ягулык майларына чылатылган кәгазь, мамык, чүпрәк калдыру;
- янәшәсендәге мәйданнарда чүп яндыру;
- көнкүреш калдыкларын ташлау.

ИРТӘ КИЛГӘН ЯЗ КУРКЫТА

Авыл хуҗалыгы

Җирнең һәр сулышын тоеп торган агрономнар әнә шулай ди. Аларның болай дип әйтүләре язгы кыр эшләрен иртәрәк башлауга гына бәйле түгел, җылылардан соң кинәт суытып җибәрергә мөмкин, ди белгечләр. Язгы чәчүгә ныклап торып керешкәнче, игенчеләрнең хәлен белештек.

Яз иртә килсә дә, әзерлек эшләре инде күпчелек районнарда төгәлләнгән. Минзәлә, Мөслим, Сарман аграрийлары кырларда уҗым культураларын тукландыруга кереште.

Кукмара районының баш агрономы Илдар Габбасов әйтүенчә, быел кырларда кар артык күп булмаса да, уҗымнар кышны уңышлы чыккан.

– Басуга ташу төшә башлады. Безнең балачакта иң күңелле чак шушы була торган иде. Башка елларда мондый һава торышы 10 апрель тирәсендә күзәтелә иде. Быел яз иртә килә. Ул куркыта, чөнки кинәт суытып җибәрү куркынычы зур.

Кыр эшләренә килгәндә, баш агроном сүзләренчә, барысы да инде әзер.

– Әлегә зарланырлык түгел, – ди ул. – Җирләр кардан ачылгач, иң беренче эшлисе эш – печән җирен тукландыру һәм дым каплату. Ашламалар, орлыклар җитәрлек, техникалар каралган. Тик бөтен илне борчыган проблема бездә дә бар. Ул да булса, ашлыкны сата алмау. Эре хуҗалыклар да, фермерлар да борчуда. Моннан чыгу юлын күрмим. Дөрес, маллы кеше ота, игенчелек белән генә көн иткәне оттыра. Әле ярый бездә мал күп. Ашатырга була. Сатсаң, яхшы да ул, тик хакы юк бит. 6 сумга сатуның бер мәгънәсе дә юк. Симәнә алыштыру һәм мал ишәйтү өчен быелгыдан да уңышлырак ел булганы юк әле. Никтер быел язгы ярминкәләрдә бәрәңге дә сатылмый. Бу атнада 10 тонна бәрәңге алып барган идек. Гел дә сатылмаган диярлек.

Аксубай фермеры Ильяс Сөләйманов төп табышын терлекчелектән ала. Шуңа күрә аны әлеге вакытта барыннан бигрәк сөт бәяләренең түбән булуы борчый. Ә ашлыкны үзенең терлекләренә җитәрлек кенә чәчә.

– Шуңа күрә ашлыкны урнаштыруга бәйле авырлыклар миңа кагылмый, – диде ул. – Кырга чыгасы эшләрнең барысы да эшләнде. Ягулык, ашлама, орлыклар – барысы да әзер. Гомумән, безнең ише фермерларга чәчеп азапланмасаң да була. Сатып алсаң, отышлырак та, мәшәкатьсезрәк тә. Әлегә кырларда кар ята. Эре хуҗалыклар тукландыруга керешергә әзерләнә, мин ашыкмыйм әле. Быел туфракта дым җитә, диләр. Ләкин мин бу сүз белән килешмим, чөнки дым никадәр күп булса да, ул аска төшә, туфракның өске катламында калмый. Шуңа күрә орлык җиргә урнашуга ук яңгыр кирәк. Ә кар безнең якларда аз булды.

Ильяс Сөләйманов кабаттан сөт бәяләренә әйләнеп кайтып, иң нык күңелгә тигәне шул диде: «Әлеге вакытта 33 сум 50 тиеннән 24 сумга калды. Керем булмаса, эшне туктатырга гына кирәк. Чәч белән җир себерә торган чаклар узды инде».

Арчаның «Казанка» хуҗалыгы җитәкчесе Айдар Сабировның кәефе күтәренке.

– Бездә басуга керергә иртәрәк. Якынча ике атна тирәсе вакыт кирәк. Районда тукландыруга да керешә алмыйлар әле, чөнки җир бик юеш. Төнлә катырмагач, берникадәр авырлык бар. Үзебезнең чәчү мәйданнары үзгәрмәде: 1750 гектар бөртекле культуралар чәчәм. Ашлыкларны узган көздә үк сатып бетергән идем. Бәясе арзанрак булса да, субсидия булгач, мин канәгать.

Районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Ленар Абдуллин да техника, орлыкларның әзер булуын әйтте.

– Узган ел чит ил техникасына запас частьлар кайтартуга бәйле авырлыклар булгач, быел алдан хәстәрен күрдек, – диде ул. – Тик ашлык яхшы бәядән вакытында сатылып беткән һәм сөткә бәяләр кинәт һәм шактый төшмәгән булса, язгы кыр эшләренә керешеп китү җиңелрәк булыр иде. Күп хуҗалыклар сөткә өмет баглап тора бит. Ә аның бәясе төште. Хәзерге вакытта складларда да 54 тонна ашлык бар. Шулай да Арча районы кыр эшләрендә сынатмас. Узган атна ахырында хуҗалыклар район башлыгы каршында планнарын якладылар.

«Татар-информ»

Фикер

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының игенчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы Ирек САДЫЙКОВ:

– Хәзерге вакытта районнарда орлыклар кайтару һәм тикшерү эшләре алып барыла. Бүгенгә 15 район уҗымнар һәм күпьеллык үләннәрне тукландыру өчен кырга чыкты. Уңыш язның иртәме яки соңмы килүенә бәйле түгел. Быел язгы кыр эшләре асылда узган елдагы кебек 15 марттан башланды. Чәчүгә кайчан керешү исә һава торышына һәм явым-төшемгә бәйле. Узган елда ул – 22 апрельдә, мул уңышлы 2020 елда 3 апрельдә башланды. Бездә чәчү эшләренә гадәттә апрельнең беренче-икенче декадасында керешәләр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ТЕЛӘК БУЛСА, БЕЛӘК ЧЫДАР

Бәйге

«Ел укытучысы – 2023» бөтенроссия бәйгесенең республика этабы җиңүчеләре билгеле. Алар арасында үз эшенең остасы булган татар теле һәм әдәбияты, башка фән укытучылары да, тәрбиячеләр дә бар. Ә «Ел укытучысы» булу бәхете Югары Ослан районының Иннополис лицеенда белем бирүче 28 яшьлек математика укытучысы Арман Костанянга елмайды. Сентябрьдә ул Мәскәүдә узасы илкүләм бәйгедә Татарстан данын яклаячак.

Башка еллардан аермалы буларак, быел бәйге өч турда узды. Укытучылар дәрес, мастер-класс күрсәтте, педагогик советта катнашты. «Ел укытучысы» номинациясендә – 45, «Педагогик дебют» юнәлешендә 21 мөгаллим көч сынашты. Яшь укытучылар арасында җиңүне Казандагы 21 нче гимназиянең биология, химия укытучысы Карина Абаза яулады.

– Мәгариф системасында төп фигура – укытучы. Алар бүгенгене дә, киләчәкне дә кайгырта. Укытучыларның дәрәҗәсен күтәрү өчен, республикада күп эшләр башкарыла. Алар арасында кемнәр генә юк: хатын-кызлар да, ирләр дә, яшьләр дә, төрле фән укытучылары да. Бәйгедә катнашучыларның уртача яше – 38. Иң яшенә – 21, иң өлкәненә – 57 яшь. Әгәр үз эшеңне яратмасаң, әти-әниләр белән эшли белмәсәң, монда чыгып, кәгазьгә карап сөйләп утырудан гына файда юк, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин чараның ябылу тантанасында.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова бәйгедә җиңгән иң яхшы тәрбиячеләрне котлады. Татар телле төркемдә эшләүчеләр арасында беренче урынны башкаладагы 41 нче бакча тәрбиячесе Айсылу Лотфуллина алды. Казандагы 101 нче бакча тәрбиясе Юлия Токмакова «Ел тәрбиячесе» булып танылды.

– Тәрбияче – баланың борын астындагы юешен сөртүче, җырлар җырлаучы гына түгел, бик зур шәхес. Сабыйларга барысын да аңлатучы, ватанпәрвәрлек орлыклары салучы, үз туган җиренә хөрмәт уятучы да, – диде Римма Ратникова, аларны зурлап.

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Татарстанның иң яхшы укытучысы булып Арман Костанян танылды.

Татарстан Иҗтимагый палатасы рәисе җитәкчесе Зилә Вәлиева әйтүенчә, укытучы белем генә түгел, тәрбия дә бирә.

– Әгәр акча эшли беләсең икән, син – герой. Бер мәлне шундый бер чор булды. Укытучыларның тырышлыгы белән башкаларга ярдәм итә белгән, Ватан язмышы өчен борчылган кешеләрнең бәясе артты, – дип белдерде Зилә Вәлиева.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров татар теле укытучыларын котлады. Татар теле бәйгесендә илнең 12 төбәгеннән 12 укытучы катнашты.

– Республикадан читтә яшәүче милләтләрнең карашлары Казанга төбәлгән. Андагы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бәйгедә катнашуы безнең өчен таяныч. Алар ана телен укыту белән генә чикләнми, милләт баласын тәрбияли, татар икәнлеген сеңдерә, – диде Данис Шакиров.

«Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия бәйгесенең җиңүчеләре – Төмән шәһәренең 52 нче урта мәктәбе укытучысы Халидә Кирамова һәм Казанның татар телендә белем бирүче 13 номерлы гимназиясе укытучысы Алинә Шәгәрәева.

Халидә Кирамова Төмәндә сигез милләт баласына татар телен өйрәтә. «Укытучы күңел биреп эшләсә, нәтиҗәсе дә бар. Татар теле дәресләре балалар өчен искиткеч бер ачыш булырга тиеш», – диде ул.

Алинә Шәгәрәева мәктәптә 15 ел эшли. Ул тумышы белән Спас районыннан.

– Көч-куәт бетеп барганда, үзеңне кулга алып, яңа дәрт белән тотыну иң авыры булгандыр. Бик катлаулы бәйге, кискен көрәш барды. Теләк булса, беләк чыдар, диләр. Аллага шөкер, уңыш белән тәгәлләнде. Укучыларым, әти-әниләрем дә сөенде. Алар минем өчен борчылып торды, – диде Алинә Шәгәрәева, сөенече белән уртаклашып.

Мөслим районының Күбәк мәктәбе директор урынбасары, татар теле укытучысы Дилбәр Гарифуллина «Традицияләр һәм яңалыкка омтылыш» номинациясендә җиңде. Аның да фикерләрен сораштык.

– «Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» бөтенроссия һөнәри бәйгесендә 2018 нче елда катнашкан идем. Ул елны 3 нче урын алдым. Быел тагын көчемне сынап карарга булдым. Бәйгегә яңалыкка омтылуым китерде мине. «Адымнар» күптелле мәктәбендә 8 нче сыйныф укучыларына Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы кысасында «Күңел җәүһәрләре» темасына сыйныф сәгате күрсәттем. Ә дәресем Казимир Малевичның супрематик картиналары нигезендә Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» әсәрен анализлауга багышланган иде. Мастер-классымда һәм методик остаханәмдә иҗади эшләүче укытучы буларак, уку грамоталылыгын формалаштыру, креатив фикерләүне үстерү буенча эш алымнарымны тәкъдим иттем. Татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып 30 елдан артык эшлим. Укытучы ул – һәрвакыт эзләнүдә. Эзләнүләр көчле булса, табышы да көттерми, – диде Дилбәр Гарифуллина.

«Ел укытучысы» булып танылган Арман Костанянның мәктәптә эшли башлавына – 6 ел. Укытучылар сафына очраклы рәвештә генә килеп эләккән. Әмма бу һөнәрне сайлавына бер дә үкенми. Өч ел элек бәйгенең «Педагогик дебют» номинациясендә җиңгән.

– Иң мөһиме – укучыңның җиңүен, уңышын күрә белү. Олимпиада, бәйгедә җиңгән укучыларым өчен горурлык кичерәм. Укытучы булу – көттәлек ул, дип балаларга еш кабатлыйм, һөнәремнең дәрәҗәсен әнә шулай күтәрергә тырышам. Балалар белән эшләүдән ләззәт алам. Гади укытучы булу гына җитми, замана укытучысы булырга кирәк, – диде Арман Костанян.

Сәрия МИФТАХОВА

Онлайн сатканы шалтыратмый

Маркетплейста сатучы беркайчан да сезнең белән элемтәгә керми! «Вайлдберриз», «Озон» кебек интернет-кибетләрдән әйбер сатып алырга яратучылар шушы кагыйдәне истә тотарга тиеш, ди белгечләр. Ник дигәндә, соңгы арада мошенниклар халыкны төп башына утыртуның яңа ысулын уйлап тапкан.

Алар, кешенең маркетплейстагы сәхифәсен ватып, анда күрсәтелгән номерга: «Техник сәбәпләр аркасында соңгы заказыгыз өчен түләү кабул ителмәде. Акчагыз кире кайтарылды. Заказны яңадан рәсмиләштерү өчен фәлән номерга (счетка) акча җибәрүегезне сорыйбыз», – дигән смс-хәбәр җибәрә. Кайберәүләргә шулай дип шалтыратучылар да булган.

«Банки.ру» порталының социаль-икътисадый һәм лайфстайл контент буенча белгече Салават Йосыпов белдерүенчә, интернет-кибеттән әйбер сатып алганда алданмас өчен, гади генә кагыйдәне истә калдырырга кирәк.

– Сатып алынган товар өчен түләү, товар кайтаруга бәйле барлык операцияләр маркетплейстагы шәхси битегездә генә башкарылырга тиеш. Андагы сатучылар сезнең белән беркайчан да турыдан-туры элемтәгә чыкмаячак. Шуңа күрә үзен фәлән интернет-кибет белгече дип шалтыраткан, смс-хәбәр җибәргән кеше белән аралашуны шундук өзәргә кирәк. Товар алу, товар кайтаруга бәйле сорауларыгыз булса, маркетплейсның техник ярдәм хезмәтенә мөрәҗәгать итегез, – ди ул.

Белгеч «Вайлдберриз», «Озон» кебек интернет-кибетләрдә шәхси бите булган кешеләргә әлеге кушымтага керү өчен, ким дигәндә, 12 төрле символ кергән катлаулы пароль куярга киңәш итә.

– Банк картагыз беркетелгән һәм сезнең турында шәхси мәгълүмат сакланган барлык аккаунтларга гадәти логин-парольдән тыш, өстәмә пароль куегыз. Анысы телефонга, электрон почтага яки шул кушымтага смс рәвешендә киләчәк. Смс аша килгән парольне беркемгә дә күрсәтергә, әйтергә ярамый, – ди Салават Йосыпов.

Хәтерләсәгез, мошенникларның халыкны алдауның тагын бер ысулын уйлап табуы турында язган идек. Алар, банк клиентларына шалтыратып, үзләрен ФСБ хезмәткәре дип таныштыра. Шуннан соң аларның исеменнән Украина армиясенә акча күчерелүе турында хәбәр итә. Имеш, банк хезмәткәрләре, клиентларының шәхси мәгълүматларын урлап, алар исеменнән акча күчереп ята. Алай гына да түгел, кырыгалдарлар, тиз арада ни дә булса эшләмәсәгез, җинаять җаваплылыгына тартылачаксыз, дип ышандыра. Моны булдырмас өчен дип, кешене «куркынычсызлык хезмәте»нә кушылып, карталарындагы акчаны алар счетына күчерергә мәҗбүр итәләр икән.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

СҮЗ УҢАЕННАН

Татарстан телефон аша алданулар иң күп теркәлгән өч төбәк арасында кала бирә. Республика халкы дистанцион рәвештә эш итүче мошенникларга атна саен 20 миллион сум акча күчерә. Быелның ике аенда телефон аша кылынган 2,5 мең җинаять теркәлгән инде. Мондый юл белән кылынган җинаятьләрнең дүрттән берен банк картасыннан акча урлау, халыкны мәгълүмати технологияләр ярдәмендә алдау очраклары тәшкил итә.

Ватан хакына!

ИСӘНМЕ, УЛЫМ!

Балтач

Махсус хәрби операциягә чакырылган егетләр ялга кайта. Якыннары гына түгел, алар үзләре дә шатлыктан күз яшьләрен тыя алмый. Барысында да бер теләк: исән-имин булып, бөтенләйгә кайтырга насыйп булсын!

Балтач районы Нөнәгәр авылы егете Инсаф Гарипов, өлешчә мобилизация игълан ителеп, берничә көн үтүгә, 26 сентябрьдә үк хәрби хезмәткә чакырыла.

– Казанда эшләсә дә, пропискада авылда булгач, чакыру безгә килде. Чыгарып җибәрү җиңел булмады, әмма ризалаштык инде. Бер айга якын Казанда өйрәнүләр уздылар, аннан соң Луганск өлкәсенә алып киттеләр. Ул кечкенәдән бик тыйнак, акыллы булып үсте. Ике улым да армиядә хезмәт итте, анда да барысы да әйбәт дип кенә әйттеләр, безне беркайчан борчымадылар. Әле дә бернәрсәдән зарланмады. Бөтен нәрсә бар, ярдәм дә күп килә, диде. Үзебез дә ашамлык, кирәк-яракны исемләп, үзенә атап та, болай да җибәрдек. Исемлеләре дә үзенә барып җитте. Нәрсәдер җибәрә алгач, барып җиткәнен белгәч тә күңелгә рәхәт була инде. Өч-дүрт көнгә бер шалтыратышып тордык. Күп сүзле түгел, телефоннан ялгышып та авыр дигәне булмады, гел барысы да әйбәт ди. Ул әйбәт дигәнгә карап кына әни кешенең күңеле тыныч тормый инде… Ялга кайтуы көтелмәгән зур бүләк булды. 11 март көнне, алдан берни әйтмичә, сюрприз ясап кайтып керде. Интернетка видеолар куялар бит әле, төшерсәң, безнеке дә нәкъ шундый буласы иде… Сөенечтән егылмадыңмы, дип сораучылар да булды. Егылмадым. Санаулы көн тиз үтә, китәр көне дә җитә инде. Әмма бер күрешкәч, сөйләшкәч, барыбер йөрәккә рәхәт булды. Тиз арада бөтенесенә исән-имин булып, бөтенләйгә кайтырга насыйп булсын, дип телибез инде, – ди әнисе Рәмзия ханым.

Бу көннәрдә Нөнәгәргә тагын бер егет – Рәнис Гафиуллин да ялга кайта. Хәрби хезмәткә ул Инсафтан соңрак китә, Казанда ике айлап өйрәнүләр уза, декабрь азагында хәрби хәрәкәтләр булган тарафка алып китәләр. Инсафтан аермалы буларак, Рәнис инде гаиләле. Тормыш иптәше Рашидә белән ике яшьлек кызлары үсә.

– Улыбыз Казанда, вахта ысулы кебек, сөт ташый торган машинада эшләде. Унбиш көн эшли, унбиш көн ял итә. Алар күрше Чутай авылында башка чыгып яшиләр. Чакыру да шунда килде. Ул ике ел армиядә хезмәт иткәч, контракт буенча да бер елга барып кайткан иде. Шуңа күрә бармыйм дигән сүзе дә булмады. Армиядә механик-йөртүче булган иде, монда укчы булып хезмәт итә. Ике тапкыр унар көнгә алгы сызыкка кереп чыктылар, анда кергәндә элемтәгә чыга алмый инде, ә мондый вакытта көн саен бер шалтыратып, хәлләр белешә идек. Зарланмады, ашау-эчү дә бар, кыр кухнясы да эшли, ярдәм дә килә, диде. Кайтасын балалар белгән-ишеткән булган, миңа әйтмәделәр. Бик сөендек! Ай ахырында кабат китә, түземсезләнеп бөтенләйгә исән-сау кайтуын көтәрбез инде, – ди әтисе Рәкыйп.

– Мин кайткан хөрмәткә дип, Коръән ашы үткәргән идек, – дип, соңрак Рәнис үзе дә элемтәгә чыкты. – Без Балтачтан 36 кеше киткән идек. Бәхеткә, күбебез бер урынга эләктек. Ялга да 9 кеше бергә кайттык. Якташлар күп булгач, хезмәт итү җиңелрәк. Сөйләшергә уртак сүзләр, темалар да күп. Авылдагыларга да аралашып торырга уңайлы. Алгы сызыкка кермәгәндә без бер авылда яшибез. Командирлар бик әйбәт. Рәхмәт яусын, райондашлар да онытмый, Айдар Хисмәтуллин җитәкчелегендәге егетләр безнең янга дүрт тапкыр гуманитар ярдәм алып килде инде. Алар килгәч, туган якка кайткан кебек буласың. Ашау-эчүләрдән зарланырлык түгел. Кыш та салкын булмады. Әмма барыбыз да тизрәк туган якларга кайту турында хыялланабыз инде. Кызым Диләрә дә бик сагынган. Ике яшьтә генә булса да, аңлый шул инде, янымнан да китми.

«Якташлар күп булгач, хезмәт итү җиңелрәк. Сөйләшергә уртак сүзләр, темалар да күп», – ди Рәнис.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Авыл язмалары

Абзар

Безнең ишегалдында бик иске мал абзары бар. Быел көз шуны сүтеп ташлыйм дип кызып йөрдем дә шул көе калдырдым. Яздан сүтсәң, арурак агачларын эшкә яратып була, көздән сүтсәң, су эчеп кенә яталар. Шулай дип акланган булдым. Чын сәбәбе ул гына түгел иде бугай. Кадерле ул миңа ничектер…

Мин бәләкәй чакта әни төзетте аны. Кемдер кайсыдыр яктан күреп кайткан да үзе эшләп куйган, аннан күреп, бүтәннәр төзегән. Шул рәвешле, бер-бер артлы «турыга эшләнгән» мал сарайлары калкып чыга башлады. Зур ул шундый. Сәндерәсе йортның икенче каты шикелле итеп төзелгән. Элек гел өчпочмаклы сәндерәләр иде бит, ә бу дүртпочмаклы, шундый уңайлы, әллә күпме печән сыя. Әни дә кызыккандыр инде, ничек итсә иткән, төзеткән…

Аны төзегән чакларын мин ярты-йорты гына хәтерлим, кечкенә малай идем. Тик бөтен гомер шунда узды бугай. Мал караулар, тирес чыгарулар… Сыер бозаулаганын көтеп, төннәр буена саклап чыгулар. Сарык бәтиләрен күтәреп йөртүләр. Малларга җылырак булсын дип, көзләрен балчык сылаулар да, батып ятмасыннар дип, идән җәюләр дә калмады. Үгез җимергән улакларны төзәтүләр дә… Монысы үзәккә үтә башласа, мин, эчтән генә сүгенеп, үгезгә йодрык төя-төя сугым чорын көтә идем дә шул вакыт җиткәч, кызганып, аңа ачулануым өчен үкенеп йөри идем. «И-и, ачуланырлыклары бармыни инде, гомерләре дә күпме генә бит…»

Ул абзарның коридор шикеллерәк урынында минем җыелмалы спортзалым да бар иде әле. Аның бер як стенасында – сәнәк сабына дип алып кайткан таллардан ясалган «стенка» җайланмасы. Монда эч мускулларын ныгытып, сыгылмалылык өчен күнегүләр ясап була. Ике капчык арасына таяк куеп эшләнгән «штанга» да шунда ята, ком һәм салам тутырылган төрле зурлыктагы капчыклар да эленеп тора. Икенче якта – шомартылган егермеле тактаны стенага беркетеп ясалган макивара. Аның сүс җеп белән бәйләнгән очы инде минем кендектән генә калган. Үзем дә үскәнмендер, абзар да җиргә чүгеп бара. Ул үзенә күрә бер шәхси почмак, әкият дөньясы шикеллерәк биләмә иде.

Мал асрау өчен абзарның үзен дә һәрдаим төзәтеп, карап, тәрбияләп торырга кирәк. Син аны хәстәрлисең, ул малларыңны хәстәрли. Мал асрау ул хайваннарны карау гына түгел… Син үз җылылыгыңны малларыңа да, абзарыңа да бирәсең, абзар – малларны, маллар абзарны җылыта, аларның шул җылылыгы синең дөньяңны, тормышыңны җайлый, җылырак, шатлыклырак, тулырак итә. Табигатьтәге әйләнеш шикеллерәк нәрсә барлыкка килә.

Мал асраган чакларда бу абзар да караусыз тормады. Хәтта дәверләр үзгәреп, авылда мал-туар тотучылар сирәкләнгәч тә, ул сарай вазыйфасын да, келәт вазыйфасын да үтәде. Хәзер инде менә җиргә чүгеп бара. Заманында һушыңны алырлык зифа кызларның әби чагы шикеллерәк… Шул абзарны әкият иле иткән малай үзе дә илледән өстә.

Шуңа күрә, ул миңа кадерле булып тоела. Гомеремнең бер өлеше бит инде. Малларны гына түгел, үземне дә карап үстергән җир. Тәүге хыялларым шуның тирәсендә әвәләнгән, аның аша мин бик күп нәрсәләргә өйрәнгәнмен, малайдан үсмергә, егеткә, ир-атка, узаманга әверелгәнмен. Аны сүтмичә торуымның, озаграк яшәтергә теләвемнең сәбәбе дә шул бугай.

Тик соңгы бер-ике елда мин аны карамый башладым. Сүтәргә дигән нәрсә бит инде, берьюлы сүтеп тә, яңартып та булмый. Башка елларда алай булганы юк иде, быел яз менә шул абзар эчен су баскан. Тездән. Тирә-ягында җыелып яткан күлләвек шикелле нәрсә дә юк аның. Су бары тик абзар эчендә генә. Бу миңа беркадәр сәер дә, кызганыч та булып тоелды. Балалары исән көенә караучысыз яткан аналарга да охшатып куйдым. Тормышның бөтен михнәтләре әнә шундый ташланган, яклаучысыз калганнар өстенә җыела бит инде. Үзеңне карап үстергән, тәрбияләгән, кеше иткәннәрне караучысыз калдырырга ярамый икән. Хәтта ул гади генә абзар булса да.

Көннәр җылыну белән сүтеп ташлыйм. Әгәр аның гомерен озайтып булмый икән, үлемен, әҗәл алды тартышуларын сузарга ярамый.

Марат КӘБИРОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Төбәкара клиника-диагностика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе Системалы медицина һәм сәламәтлек архитектурасы институтының бюджеттан тыш эшчәнлек буенча әйдәүче фәнни хезмәткәре, профессор, химия фәннәре докторы **Жданов** Ренад Ибраһим улына **«Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Казан шәһәренең «11 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең неврология бүлекчәсе табиб-неврологы **Арефьев** Игорь Александровичка, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең 2 номерлы микрохирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-офтальмологы **Гатауллин** Айдар Гамил улына, Казан шәһәренең «7 номерлы шәһәр балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлекчәсе мөдире – табибы – аллерголог-иммунологы **Круглова** Елена Борисовнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының профессор Е.В. Адамюк исемендәге Республика клиник офтальмология хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең микрохирургия бүлекчәсе мөдире – табиб-офтальмологы **Сабирова** Илсөяр Хөрмәтулла кызына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М. Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлекчәсе мөдире – 1 номерлы психиатрия көндезге стационары табиб-психиатры **Тугарина** Гөлнара Рамил кызына, Казан шәһәренең «11 номерлы шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының медицина часте буенча урынбасары **Хәбибуллина** Рәмзия Тәлгать кызына, «Казан шәһәренең дезинфекция станциясе» муниципаль бюджет учреждениесенең тулы дезинфекция уздыру һәм санитар эшкәртү бүлеге табиб-дезинфектологы **Шакирова** Дания Гариф кызына **«Татарстан Республикасының атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КОНТРАКТ БУЕНЧА ХӘРБИ ХЕЗМӘТ

РФ ОБОРОНА МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН КОНТРАКТ ТӨЗЕГӘЧ, БЕР ТАПКЫР ТҮЛӘНЕЛӘ:

195 000 сум

Махсус хәрби операциядә катнашкан өчен өстәмә түләүләр каралган

Хәрби комиссариатка мөрәҗәгать итү өчен:

8 (843) 221-44-52



Гаптерәхимовларның шәхси архивыннан

Яшел Үзән районы Татар Танае авылында яшәүчеләр көймәләрен чыгарган.

ЯРЛАРЫННАН ТАШСА ЕЛГА...

Яз галәмәте

Бу елларда әле тегеннән, әле моннан авылларны су басу турында хәбәрләр килеп ирешә. Көннәрнең кинәт җылытып җибәрүе, төнлә дә температураның нормадан югары торуы, яңгырлар үз эшен эшләде.

«Су басар дип көтсәк тә, болай тиз булыр димәгән идек», – ди Балтач районының Борнак авылында яшәүче Зөлфия Мөбарәкшина.

– Әле ярый көннәр җылы тора башлагач, баздан бәрәңгене чыгардык. Шушма елгасы артык күтәрелмәс төсле иде. Кар да бетте бит. Су әллә каян килеп чыкты. Яңгырның хикмәте булгандыр инде. Мунча, сарайларга, өй астына су керде. Идәнгә чыкмаганга сөенеп торабыз, – ди ул. – Ел да шушы хәл бит инде. Әллә быел коры калырбызмы дигән идем – булмады. Аргы як урамдагы барлык кешегә су керде. Идән астындагы су өчен борчылмыйм, көзгә бетә инде ул.

Борнак егете Ренат Галиәскәров белән дә сөйләштек. Ул бу елларда авылга кайткан. Шушманың күтәрелүен күреп гаҗәпләнгән.

Ренат Галиәскәровның шәхси архивыннан

Балтач районы Борнак авылының бер урамын су баскан.

– Авыл халкының исе дә китми су басуга. Гадәтләнгәннәр инде. Авылдагы башка урамнарның бакчаларына гына килә бу су. Ә менә Аргы якны бер дә буш калдырмый. Элек алар кечкенә елга аша көймә белән дә йөриләр иде. Асылмалы күперне яхшысына алыштырдылар. Быел шуны да су баскан. Әмма резин итек киеп чыгып була икән. Ул урамда яшәүчеләр алдан хәстәрен күрә. Техникаларын бу якка чыгарып куя. Язгы ташу вакытын матур гына үткәреп җибәрә беләләр, – ди ул.

Яшел Үзән районы Татар Танае авылында яшәүче Рабига Баһавиева йортына быел су кермәгән. Аның каравы, Гөбенә күтәрелеп, башка якта яшәүчеләрне су баскан. Авыл җирлеге башлыгы әйтүенчә, быелгысы алай куркыныч түгел икән. Түзәрлек, ди ул.

– Кечкенә елгалар күтәрелмәде. Гөбенә дулый, ярларыннан ташый. Авылның Вахитов һәм Ленин урамнарында яшәүчеләрнең бакчаларына, йортларына су керде. Кар да беткән иде бит инде. Әллә каян су килеп төште. Икенче елга бу хәлләрдән котылачакбыз инде. Авылга су кермәслек итеп юл ясап куячакбыз, – ди ул.

Шушы авылда яшәүче Гаптерәхимовларның тавыкларына кадәр, тактага басып, суда йөзә. Алдан әзерләнеп куйсалар да, су үзенекен иткән.

– Идәннән су чыгарга 25 сантиметр калды. Быел бу су басу түгел әле. 2018, 2020 елларда көчлерәк иде. Ул чакта да күңелне төшермәдек, – ди Рәшит абый. – Әти 1904 елгы. Ул шушы нигездә гомер иткән. Без монда 1964 елның мартыннан бирле яшибез. Элек су басу юк иде ул. Бездә миллионер колхоз иде бит. Шуны җитәкләүче кеше авыл халкы өчен дип яхшы юл салдыртты, дамба ясатты. Су юлы капланган, ахры. Хәзер яз саен дамбаның бер ягындагы кешеләрне су баса. Шуны ясасалар, без дә тилмермәс идек.

Рәшит абыйларның мунча ләүкәләренә кадәр су кергән. Кетәклектәге тавыкларына биек агач поддонннар алып кайтып куйган булган. Алар шуңа утырып йөзеп йөри икән. Үзе исә балыкчы итеген сөйрәп чыгарган. Идән асларында берни калдырмаганнар. Ел саен яз җитүгә, кайгыра башлыйбыз инде, ди.

– Күршедә көймә бар. Кирәк чакта шуңа утырабыз. Авылда 20ләп хуҗалыкка су керде быел. Бер ияләшкәч, моңа аптырамыйбыз да инде. Шулай күнеккәнбез. Өебездән 200 метрда Гөбенә елгасы күренеп тора. Бүгенге хәле – артыңа борылып карасаң, диңгезгә килеп эләккән төсле, – ди ул. – Су юлына комачау итмәсәләр, агып китә иде ул. Су юлына агачлар авып, каплап бетергән. Әле менә күрше белән барып, шуларны тракторга тагып өстерәтеп алдык. Авылдашлар, әкренләп су кими, дип хәбәр иттеләр. Бер генә теләк: катырак басмасын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

СУ БАСКАНДА НИШЛӘРГӘ?

- ✓ Тәрәзә-ишекләрне ябарга яисә такта кадакларга.
- ✓ Кыйммәтле әйберләрне чормага яисә өйнең өстәге катына менгезергә.
- ✓ Су үткәрми торган пакет (капчык) эченә өске кием, документлар, акча, дару, су, азык-төлек, гигиена кирәк-яракларын салып, әзерләп куярга.
- ✓ Су кимегәч: су астында булган азык-төлекне кулланмаска, су кергән коелардан эчмәскә, киселгән яисә асылынып торган электр чыбыкларына тимәскә, сак булырга.
- ✓ Су киткәннән соң, йорт эченә кергәч, бүлмәләрне җилләтергә кирәк. Яктырту максатыннан ут кулланмаска, бары тик фонарь ише җайланмалардан гына файдаланырга.

Мөнәсәбәт

Чикле мөмкинлек, чиксез теләк

Дәресләрдән соң такси чакыртырга туры килде. Күз ачып йомганчы, миңа дигән машина килеп тә җитте.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Радиодан татарча җыр ишеткәч, машина йөртүчедән: «Сез кайдан?» – дип сорарга булдым.

– Тумышым белән Мамадыштан, әмма Казанда 40 ел яшим инде, – диде ул.

Юл буе сөйләшеп бардык. Таксистларның төрлесе очрый. Гадәттә мин радио тыңлап, уй-фикер дәрьясына батам. Әмма бу юлы әлеге машина йөртүчегә игътибар итмичә булдыра алмадым.

Күзем аның кулларына төште. Карасам, газ һәм тормоз педальләренә аяклары белән басасы урынга, машина белән ул руль янында урнашкан җайланмалар ярдәмендә идарә итә икән. Димәк, кузгалып киткәндә, туктаганда да ул гадәттәгечә аяклары белән түгел, ә куллары белән эшли: машина йөртү ысулларын үзенә җайлаштырган. Беренче тапкыр күргәч аптырадым. Ичмасам, транспортка куела торган «Мөмкинлеге чикле» билгесен дә күрми калганмын. Ә аның аякларын паралич суккан икән.

Бу мөмкинлекләре чикләнгән таксистлар өчен махсус машина булып чыкты. «Менә бит, әгәр кешегә эш кирәк икән, ул моның өчен төрле мөмкинлек табачак. Бу таксист та үз көче белән, намуслы рәвештә эшли», – дип уйлап куйдым. Җитмәсә, ул шигырьләр дә яза икән, тик менә популярлык түгел, ә үзе өчен. Шуңа үзе турында кычкырып сөйләүләрен теләми.

...Гади генә таксида бару уйланырга мәҗбүр итте әле. Кайвакыт без тормышның вак-төяк мәшәкатьләреннән зарланабыз. Ә менә бу машина йөртүче аягын паралич суккан килеш тә, гадәти тормыш алып баручы кеше сыман, уфтанмыйча таксида эшли. Батыр, кыю кешеләр безнең арада да бар икән бит! Физик мөмкинлеге чикле кешене сау-сәламәт булган башкаларга үрнәк итеп куярга була.

Диана КАРПОВА

Футбол

	Команда	уен	очко
1	Балтика	24	51
2	**Рубин**	**24**	**45**
3	Енисей	24	42
4	Алания	24	41
5	Арсенал	24	36
6	Шинник	24	35
7	Волгарь	24	35
8	СКА-Хабаровск	24	34
9	КАМАЗ	24	33
10	Динамо Мх	24	33
11	Родина	24	31
12	Акрон	24	30
13	Нефтехимик	24	29
14	Велес	24	24
15	Кубань	24	24
16	Уфа	24	21
17	Волга Ул	24	20
18	Краснодар-2	24	17

rubin-kazan.ru

ИСКЕ ЯҢА КӨНДӘШЛӘР

КАЗАН КОМАНДАСЫ ГАГАРИН КУБОГЫ ӨЧЕН КӨРӘШӘ

Спорт

Татарстанның хоккей җанатарлары өчен якшәмбе күңелле хәбәрдән башланды. «Ак барс» командасы Владивостокның «Адмирал»ын җиңеп, КХЛның көнчыгыш конференциясе финалына үтте. Зиннәтулла Билалетдинов җитәкләгән команда көндәшләрен алтынчы матчта 1:3 исәбе белән отты. Алда иске яңа дуслар – Омскиның «Авангард»ы. Соңгы елларда Казан клубы алар белән еш очраша.

«Адмирал» командасы баш тренеры Леонид Тамбиевның хыялы тормышка ашмады. Алтынчы матч алдыннан ул: «Әле җиденче уен да булачак», – дип илһамланган иде югыйсә. Билалетдинов һәм аның командасы исә озаккарак сузылган сериягә көндәшләр бозында нокта куеп, җиңү белән Казанга кайтып китте.

Сүз дә юк, плей-офф башында «Салават Юлаев» командасын җиңгән, «Ак барс» өчен дә җиңел уен күрсәтмәгән, бу сезонда күпләрне гаҗәпләндергән Владивосток командасына да мактау сүзләре әйтми мөмкин түгел. Тырыштылар, көрәштеләр, үҗәт булдылар, кызык уен күрсәттеләр. КХЛдагы «топ» саналган командалар рәтендә тормасалар да, теләк һәм бердәмлек барда нәтиҗәгә ирешергә мөмкин икәнен исбатладылар. Боздагы уенчыларны гына түгел, «Адмирал»ның тренерларын күзәтү дә бер тамаша булды. Леонид Тамбиев та журналистлар белән ачылып сөйләште. Кайбер сүзләре канатлы гыйбарәләргә әйләнмәгәе әле. «Адмирал» «йолдыз»ына әйләнгән капкачы Никита Серебряковны да аерып әйтергә кирәк. Юкка гына аны плей-оффның беренче раунды иң яхшы уенчылары рәтенә кертмәгәннәрдер.

Соңгы очрашуда «Ак барс»лар бозда кемнең хуҗа булуын уен башында ук күрсәтте. Беренче периодта ук «барс»лар өстенлек итте (2:0), икенче периодта гына «Адмирал» егетләре бердәнбер алка кертүгә иреште. Сүз уңаеннан, күбрәк алкалар кертергә мөмкинлекләре шактый иде. Өченче периодта көндәшләр күп вакытын «барс»ларга һөҗүм итеп уздырды, әмма исәп арасын кыскарта алмады.

ak-bars.ru

«Ак барс»ның өстен чыгуына дисциплиналы уйнаулары (үз капкалары янында аеруча), актив хоккей күрсәтүләре, матч башында ук дилбегәне үз кулларына алулары ярдәм иткәндер, күрәсең. Казан клубына матч башында һәм азагында нәтиҗәгә китергән голлар керткән Никита Дынякны аерып әйтергә кирәк. 25 яшьлек уенчының бу – Гагарин Кубогы өчен көрәштәге тәүге дубле. Якшәмбе уенына капитан Александр Радулов кайнарлык өстәп торды: әле көндәшләр белән сүз көрәштерде ул, «Адмирал» капкачысына да эләкте. Сүз уңаеннан, Леонид Тамбиев та аны озак истә тотар бугай. Матч беткәч: «Башка командада нәфрәт уяткан уенчы – яхшы уенчы. Бу сериядә Радуловны җенем сөймәде. Безнең команда аны яратмады», – дип ачыктан-ачык әйтте «Адмирал» остазы.

«Ак барс» тренеры Зиннәтулла Билалетдинов, гадәттәгечә, күп сүзле булмады:

– Команда яхшы уйнады дип саныйм. Сөйләшкәннәрне үтәдек. Очраклы нәтиҗә түгел бу. Көндәш тә яхшы уйнады. Һәм бүген генә түгел. Барлык матчлар да җиңеллрдән булмады. Күп эшләргә туры килде. Әзерлек хисабына җиңә алдык, – диде остаз. Өстәп әйтерлек тә түгел.

Хәзер «Ак барс» Омск командасы белән көрәшкә әзерләнә. Казан уенчыларына узган сезон өчен бурычны кайтарырга яхшы мөмкинлек инде бу. Хәтердә яңартып үтик: көнчыгыш конференциясенең чирек финалында серия «Авангард» файдасына 4:2 исәбе белән тәмамланган иде. Гомумән, «Авангард» «барс»ларны өч мәртәбә Гагарин Кубогы өчен ярыштан кысрыклап чыгара алуга ирешкән иде. Яңа серия нәрсә күрсәтер бит. Беренче уеннар 1, 3 апрель көннәрендә Казанда узачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Халык кәефе

Ильяс ГАБДЕЛГАЗИЗОВ, мәҗлесләр алып баручы:
– Киләчәк серия турында алдан кычкырып булмый анысы. Шунысы хак: алда безне бик кызыклы очрашу көтә. Омск шәһәре хоккейны сагынган. Андагы трибуналарның көче командага уңай йогынты ясаячак дип уйлыйм. Ләкин «Ак барс» – тәҗрибәле команда. Аның яхшы уенчылары һәм, иң мөһиме, атаклы тренеры бар! Зиннәтулла Хәйдәр улының команданы җиңүгә алып барачагына бер шигем юк.

Флюра АЛИЕВА, «Ак барс»ның өлкән җанатары:
– Һәрчак җиңүгә генә өметләнәм. Мин «стаж»лы җанатар инде. Мин һәрвакыт команда белән. Читтә узган матчларга да йөрим, бер кыенлыгы юк. Курчаклар бәйләп, талисман итеп, аларны үзем белән йөртәм. Ул курчакларны инде барысы да таныйдыр. Хоккейчыларга да бүләк иткән бар. «Хоккей белән яшибез – «Ак барс» өчен җан атабыз», – дип юкка гына әйтмибез бит. Хоккейчыларыбыз – яратканнарыбыз! Тренерлары әйтмешли, намуслы хезмәт белән генә җиңүгә ирешәчәкбез.

Арабелла ВАФИНА, «Ак барс»ның иң яшь җанатарларының берсе:
– Сөенми хәл юк. Хәзер «Ак барс» – без күрергә теләгән команда! Ә хикмәт – тренерда. Зиннәтулла Билалетдинов белән безнең клуб яхшы нәтиҗәгә ирешә алды. Хоккейчыларның үз-үзләренә ышанычы артты. Зиннәтулла Билалетдинов белән егетләребез илһамланып китте һәм тагын да тырышыбрак уйный башлады. Тренерыбыз – бик якты кеше. Зиннәтулла Билалетдиновтан бердәмлек һәм җиңү энергиясе килә. Ул: «Намуслы хезмәт кенә җиңүгә илтә!» – ди. Бу сүзләр – барыбыз өчен девиз.

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5332 данә
Гомуми тираж – 15281 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 243

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+